Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXI-5**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 22 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге “Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм шушы мәгълүматларны бастырып чыгару өчен гаммәви мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” Х-6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законны, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 9 өлешен тормышка ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы “Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре” Указының 8 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге “Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм шушы мәгълүматларны бастырып чыгару өчен гаммәви мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында” Х-6 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016

елның 16 ноябрендәге XIII-6 номерлы карары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пунктны өстәргә:

“1.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүче зат тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турындагы мәгълүматлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм (яисә) гаммәви мәгълүмат чараларына муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм шушы мәгълүматларны бастырып чыгару өчен гаммәви мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмә нигезендә бастырып чыгару өчен бирелә, ул шушы карарның 1 пункты белән расланды.”;

1.2) Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләрнең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм шушы мәгълүматларны бастырып чыгару өчен гаммәви мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Нигезләмәне түбәндәге эчтәлектәге 5.1, 5.2 пунктлар белән туландырырга:

“5.1. Рәсми сайтта керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында, шул исәптән алдагы елларда, урнаштырылган мәгълүматлар:

а) бетерелергә тиеш түгел;

б) вазыйфаи зат үз вазыйфасын биләүнең бөтен чоры дәвамында ачык кулланылышта (рәсми сайтта урнаштырылган) була.

5.2. Муниципаль вазыйфа (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан аныкланган мәгълүматлар тапшырылганда тиешле үзгәрешләр аныкланган мәгълүматларны тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көненнән дә соңга калмыйча рәсми сайтта урнаштырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларга кертелә.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе                                                                И.Г.  Вәлиев